СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Наласа авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

от « 01 » июнь 2022 ел №  51

**«Наласа авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитеты аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук Наласа авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитеты аппаратында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 03 ноябрендәге 74/1 номерлы Наласа авыл җирлеге Советы карарына (18.04.2016 №17, 03.08.2021 №31 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2022 N 90-ФЗ Федераль законны кабул итүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы нигезендә Наласа авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Наласа авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитеты аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Наласа авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитеты аппаратында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 03 ноябрендәге 74/1 номерлы карарына (18.04.2016 №17, 03.08.2021 №31 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктның «в» пунктчасында «акцияләрне» сүзен төшереп калдырырга;

1.2. 13 пунктта «акцияләрне» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Наласа авыл җирлеге башлыгы И.Р.Шакирова